КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 30 июль г.Казань № 636

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында» 2014 ел, 2 сентябрь, 635 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында» 2014 ел, 2 сентябрь, 635 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 20 февраль, 103 нче; 2015 ел, 10 декабрь, 932 нче; 2017 ел, 14 ноябрь, 873 нче; 2019 ел, 10 декабрь, 1133 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Дәүләт социаль ярдәме социаль контракт нигезендә үзләренә бәйле булмаган сәбәпләр аркасында җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында халыкның тиешле социаль-демографик төркемнәре өчен билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган аз керемле гаиләләргә һәм аз керемле ялгыз яшәүче гражданнарга күрсәтелә.

Дәүләт социаль ярдәме социаль контракт төземичә түбәндәгеләргә күрсәтелә:

җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында халыкның тиешле социаль-демографик төркемнәре өчен билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән

түбәнрәк булган аз керемле гаиләгә һәм аз керемле ялгыз яшәүче гражданга, әгәр дә аз керемле гаиләнең барлык әгъзалары һәм аз керемле ялгыз яшәүче граждан яше, сәламәтлеге буенча эшкә сәләтсез булса;

тормышта авыр хәлдә калган, янгын чыгу, су басу яки башка табигый бәла-каза аркасында бердәнбер торагы һәм (яки) милке зыян күргән һәм җан башына уртача кереме 1 айга 20 000 сумнан артмаган гражданнарга.

Бу пунктның дүртенче абзацында күрсәтелгән гражданнарга дәүләт социаль ярдәме әлеге торак урыны бердәнбер яшәү урыны булу шарты белән күрсәтелә.»;

1.7 нче пунктта:

алтынчы абзацта «бер елга» сүзләрен «иң күбе 12 айга» сүзләренә алыштырырга;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мөрәҗәгать итү вакытына индивидуаль эшмәкәрлек эшчәнлеген, үзмәшгульлекне гамәлгә ашыру буенча дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә социаль контракт төзегән индивидуаль эшмәкәр, үзмәшгуль зат буларак теркәлмәгән гражданнарга бер тапкыр;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гражданның авыр тормыш хәлен җиңүенә юнәлдерелгән башка чараларны гамәлгә ашыру буенча дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә социаль контракт төзегән гражданнарга иң күбе 12 айга.»;

1.10 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.10. Бу Нигезләмәнең 1.1 нче пунктының өченче абзацында күрсәтелгән гражданнарга дәүләт социаль ярдәме күрсәткәндә (социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүдән тыш) бер тапкыр бирелә торган түләү күләме дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза биргән көнгә аз керемле гаиләнең (аз керемле ялгыз яшәүче гражданның) яшәү минимумы күләме һәм аз керемле гаиләнең җан башына уртача кереме (ялгыз яшәүче гражданның кереме) арасындагы аерма чикләрендә билгеләнә. Шул ук вакытта бер тапкыр бирелә торган түләүнең минималь күләме 100 сумнан да ким була алмый.

Бу Нигезләмәнең 1.1 нче пунктының дүртенче абзацында күрсәтелгән гражданнарга дәүләт социаль ярдәме күрсәткәндә (социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүдән тыш) бер тапкыр бирелә торган түләү күләме ялгыз яшәүче граждан өчен – 30 000 сум, гаилә өчен 40 000 сум тәшкил итә.»;

1.11 нче пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эш эзләүдә һәм социаль адаптацияләү программасында билгеләнгән вакытта эшкә урнашкан, һөнәри уку үтүдә һәм өстәмә һөнәри белем алуда дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә, шулай ук гражданның авыр тормыш хәлен җиңүенә юнәлдерелгән башка чараларны тормышка ашыруга социаль контракт төзегән гражданнар өчен социаль контракт төзегән елга кадәрге елның II кварталы өчен Татарстан Республикасында билгеләнгән эшкә сәләтле халык өчен яшәү минимумы күләменә тигез була;»;

дүртенче һәм бишенче абзацларны үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Тулы булмаган ай өчен социаль пособие күләме бу айның календарь көннәре санына пропорциональ рәвештә билгеләнә.»;

1.15 нче пунктта:

өченче абзацта «(18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаиләләрдән тыш)» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гаиләнең (гражданның) мөлкәти тәэмин ителеш дәрәҗәсе янгын чыгу, су басу яки башка табигый бәла-каза аркасында тормышта авыр хәлдә калган гражданнарга дәүләт социаль ярдәме күрсәтелгән очракта исәпкә алынмый.»;

1.16 нчы пунктның унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) яңа яшәү урынына яки социаль контракт төзегән территориаль социаль яклау органының үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган территориядән читкә киткәндә;»;

2.3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Янгын чыгу, су басу яки башка табигый бәла-каза аркасында тормышта авыр хәлдә калган гражданнар дәүләт социаль ярдәме күрсәтүдән файдаланган очракта, мондый хәлләрнең булуын раслый торган документлар (килеп чыккан факт турында акт, бәяләмә күчермәләре, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы бүлекчәсеннән белешмә кәгазе) өстәмә рәвештә тапшырыла.»;

2.4 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«хезмәт яки башка вазыйфаларны үтәгән өчен бүләкләүләр (компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрне, башкарылган эш, күрсәтелгән хезмәт, Россия Федерациясендә гамәл кылган өчен бүләкләүне кертеп) турында;

дивидендлар, шулай ук кыйммәтле кәгазьләр белән операцияләр буенча алынган процентлар турында;

эшмәкәрлек эшчәнлегеннән һәм хосусый тәҗрибәне гамәлгә ашырудан керемнәр турында;

авторлык заказы шартнамәләре буенча керемнәр турында, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә махсус хокукны читләштерү турында;

милекне сатудан, арендалаудан керемнәр турында;

транспорт чаралары турында.»;

2.5 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гражданның авыр тормыш хәлен җиңүенә юнәлдерелгән башка чараларны тормышка ашыруга дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә социаль контракт төзегәндә гариза бирүченең яшәү шартларына матди-көнкүреш тикшерүе үткәрелә.»;

2.7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. Гариза бирүченең яшәү шартларына матди-көнкүреш тикшерүен үткәрү һәм социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) матди хәлен һәм торак-көнкүреш шартларын тикшерү актын төзү гаризаны теркәгән көннән җиде көн эчендә территориаль социаль яклау органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Гаиләнең яшәү шартларына матди-көнкүреш тикшерүен үткәрү датасы турында гариза бирүче гаризаны теркәгән көннән өч көн эчендә язмача хәбәр итә.»;

3.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Гаиләне (ялгыз яшәүче гражданны) социаль адаптацияләү программасын эшләү гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү үзәге (халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәге структурасындагы гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү бүлеге) (алга таба – үзәк (бүлек)) белгече тарафыннан гариза бирүче катнашында гаризаны теркәгән көннән җиде көн эчендә социаль контракт гамәлдә булган чор өчен бу Нигезләмәнең 1 нче кушымтасында бирелгән форма буенча төзелә торган әңгәмә кәгазе нигезендә гамәлгә ашырыла.

Үзәк (бүлек) белгече гариза бирүчегә, гаризаны теркәгән көннән 10 көннән дә соңга калмыйча, социаль адаптацияләү программасын эшләү датасы турында хәбәр итә.

Гариза бирүче гаиләсенең яшәү шартларына матди-көнкүреш тикшерүен үткәргән очракта, гаиләне (ялгыз яшәүче гражданны) социаль адаптацияләү программасын эшләү үзәк (бүлек) белгече тарафыннан гариза бирүче катнашында гариза бирүченең яшәү шартларына матди-көнкүреш тикшерүен үткәргән көннән җиде көн эчендә социаль контракт гамәлдә булган чор өчен гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) матди хәлен һәм торак-көнкүреш шартларын тикшерү акты һәм бу Нигезләмәнең 1 нче кушымтасында бирелгән форма буенча төзелә торган әңгәмә кәгазе нигезендә гамәлгә ашырыла.

Үзәк (бүлек) белгече гариза бирүчегә, аның яшәү шартларына матди-көнкүреш тикшерүен үткәргән көннән өч көннән дә соңга калмыйча, социаль адаптацияләү программасын эшләү датасы турында хәбәр итә.

Гаиләне (ялгыз яшәүче гражданны) социаль адаптацияләү программасын эшләү түбәндәге очракларда гамәлгә ашырыла:

эш эзләүдә һәм гаиләнең эшкә сәләтле әгъзаларын эшкә урнаштыруда дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә социаль контракт төзегәндә бу Нигезләмәнең 2 нче кушымтасында бирелгән форма буенча;

һөнәри уку үтүдә һәм өстәмә һөнәри белем алуда, шулай ук стажировка узуда дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә социаль контракт төзегәндә бу Нигезләмәнең 4 нче кушымтасында бирелгән форма буенча;

индивидуаль эшмәкәрлек эшчәнлеген, үзмәшгульлекне гамәлгә ашыруда дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә социаль контракт төзегәндә бу Нигезләмәнең 6 нчы кушымтасында бирелгән форма буенча;

гражданның авыр тормыш хәлен җиңүенә юнәлдерелгән башка чараларны гамәлгә ашыруда дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә социаль контракт төзегәндә бу Нигезләмәнең 8 нче кушымтасында бирелгән форма буенча.»;

4.4 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Үзәк (бүлек) белгече, социаль контрактның гамәлдә булган вакыты тәмамланган көнгә кадәр бер айдан да соңга калмыйча, территориаль халыкны социаль яклау органы карамагында булган документлар нигезендә социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүдән файдаланучының гаиләсен (ялгыз яшәүче затны) авыр тормыш хәленнән чыгару буенча кабул ителгән чараларның нәтиҗәлелеге турында, яки социаль контрактның гамәлдә булу вакытын озайту кирәклеге турында, яки башка чара буенча яңа социаль контракт төзү кирәклеге турында бәяләмә әзерли.»;

түбәндәге эчтәлекле 5.6 нчы пункт өстәргә:

«5.6. Территориаль социаль яклау органнары социаль контрактның гамәлдә булу вакыты тәмамланган көннән өч ел дәвамында елга бер тапкыр социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүдән файдаланучы гаиләнең (социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүдән файдаланучы ялгыз яшәүче затның) яшәү шартлары (керемнәр дәрәҗәләре) мониторингын үткәрә.»;

6.2 нче пунктның икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

6.5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.5. Территориаль социаль яклау органы тарафыннан гариза бирүченең дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә билгеләү өчен тулы булмаган мәгълүмат яки документлар тапшыру факты билгеләнгән очракта, гариза бирүчегә бүлеп бирелгән акча, социаль контракт өзелгән көннән 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, Республика матди ярдәм үзәгенең казначылык счетына ирекле рәвештә кире кайтарыла, ә кайтарудан баш тартылган очракта – гариза бирүчедән суд тәртибендә түләтелә.»;

әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасында «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Социаль яклау идарәсе (бүлеге) башлыгы» сүзләрен «Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия рәисе» сүзләренә алыштырырга;

әлеге Нигезләмәнең 4 нче кушымтасында «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Социаль яклау идарәсе (бүлеге) башлыгы» сүзләрен «Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия рәисе» сүзләренә алыштырырга;

әлеге Нигезләмәнең 6 нчы кушымтасында «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Социаль яклау идарәсе (бүлеге) башлыгы» сүзләрен «Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия рәисе» сүзләренә алыштырырга;

әлеге Нигезләмәнең 8 нче кушымтасында «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Социаль яклау идарәсе (бүлеге) башлыгы» сүзләрен «Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия рәисе» сүзләренә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин